| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.02.2019 Зур Тигәнәле авылы № 3

**Агач һәм куакларны, аларның ябалдашларын кисү, яки яңаларын утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, шул исәптән «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә

**карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 18 февралендагы 8 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны, аларның ябалдашларын кисү, яки яңаларын утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләр кертергә:

**5 бүлекне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарма комитетның карарларына һәм эшчәнлегенә (гамәл кылмавына) һәм аның хезмәткәрләренә, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренә, шулай ук «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – закон) 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга яисә аларның хезмәткәрләренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Башкарма комитетка яки җирлек Советына Башкарма комитет хезмәткәрләренең гамәлләре (гамәл кылмаулары) буенча судка кадәр тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1)муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьне теркәүнең, Законның 15_1 статьясында күрсәтелгән, вакытын бозу;

2)муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, законың 16 статьясындагы 1_3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

3)мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә гамәлләрне тормышка ашыруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралган документларын кабул итүдән баш тарту;

5)әгәр баш тарту нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, законың 16 статьясындагы 1_3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

6)муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү алу;

7)Башкарма комитет яисә аның хезмәткәренең, күпфункцияле үзәк һәм аның, хезмәткәренең, законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның яисә аларның эшчеләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләр кертүнең билгеләнгән срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, законың 16 статьясындагы 1_3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

8)муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9)муниципаль хезмәт күрсәтүне, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, туктатып тору. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, законың 16 статьясындагы 1_3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

10)муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән, яисә законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, законың 16 статьясындагы 1_3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин.

5.2. Шикаять кәгазьдә, электрон формада һәм язмача Башкарма комитетка күпфункцияле үзәккә яки халыкка хокукый белем бирүне гамәлгә ашыручы, күпфункцияле үзәкнең учредителе булган тиешле җирле үзидарә органына, (алга таба - күпфункцияле үзәкнең учредителе), шулай ук законда каралган оешмага бирелә. Башкарма комитет җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югары органга (булган очракта) бирелә яки андый орган булмаганда турыдан-туры шикаятьләр муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата булган шикаятьләр күпфункцияле үзәкнең учредителенә яисә Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән билгеләнгән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. Законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешма хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаятьләр әлеге оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

Шикаятьләр почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен файдаланып, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтын (http://alekseevskiy.tatarstan.ru) файдаланып, Татарстан

Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/) файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/) кулланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итүе вакытында кабул ителергә мөмкин.

Күпфункцияле үзәк яки аның хезмәткәре чыгарган карарларга һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата булган шикаятьләр почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәре ярдәмендә, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталын яки дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең региональ порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итүе вакытында кабул ителергә мөмкин.

Законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә карата шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен кулланып, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталын яки дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең региональ порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итүе вакытында кабул ителергә мөмкин.

5.3. Кергән шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга шикаять белдергән очракта, мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдә яисә җибәрелгән ялгыш һәм хаталарны төзәтүдә яисә билгеләнгән срокны бозуга шикаять биргән очракта, аны теркәгән көннән соң биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органың атамасы, хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты исеме, яисә муниципаль хезмәткәренең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, законның 1_1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яисә) хезмәткәрләренең исемнәре;

2) мөрәҗәгать итүче физик зат булса, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат, мөрәҗәгать итүче юридик зат булса, исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номеры), электрон почта адресы (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (адресы);

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәк яки аның хезмәткәренең, законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында белешмәләр;

4) гарызнамәче хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең, законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның

хезмәткәрләренең карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгән дәлилләр;

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре куелырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аның муниципаль хезмәт алучысы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять кабул ителгән карарны юкка чыгару формасында, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү формасында, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән түләүләр каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип табылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында алга таба үтәлергә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, законың 16 статьясындагы 1_3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин.

Шикаять канәгатьләнергә тиеш түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә бирелгән җавапта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре табылганда, шикаятьне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазифаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

2. Әлеге карарны ЗурТигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы бинасындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Зур Тигәнәле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе С.Җ.Әхмәтҗанов